**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 16 март № 149

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча өстәмә чаралар турында» 2016 ел, 27 декабрь, 1011 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча өстәмә чаралар турында» 2016 ел, 27 декабрь, 1011 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның икенче һәм өченче абзацлары, 12 нче пунктның сигезенче һәм тугызынчы абзацлары үз көчен югалткан дип санарга;

2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларда смартфоннар нигезендә мобиль трекерлар кую буенча пилот проектын Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру, шулай ук Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS системасы навигация сигналлары кулланылып эшли торган, коммерция максатларында ташулар өчен файдаланыла торган М категорияле һәм куркыныч йөкләрне ташу өчен файдаланыла торган N категорияле транспорт чараларына куелырга тиеш булган навигация чараларына таләпләрне раслау турында» 2012 ел, 31 июль, 285 нче боерыгына мобиль трекерларның параметрларына таләпләрне үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү мөмкинлеген карау турында Россия Федерациясе Транспорт министрлыгына мөрәҗәгать әзерләргә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә:

2017 елның 1 июленә кадәр җәяүлеләр чыгу урыннарында юл тамгаларын һәм автомобиль юлларының терәк челтәрендә транспорт агымнарын аерып торучы күчәр сызыкларын ясауны төгәлләргә;

гомуми файдаланудагы автомобиль юллары участокларында, беренче чиратта мәгариф оешмалары, җәяүлеләр чыгу урыннары янында, автомобиль юлларының авария куркынычы булган участокларында һәм кеше күп җыела торган урыннарда ясалма яктырту урнаштыруны дәвам иттерергә;

юл эшләре программасы кысаларында мәктәп автобуслары маршрутлары уза торган гомуми файдаланудагы автомобиль юллары участокларының транспорт-эксплуатация сыйфатламаларын күтәрү өчен чаралар үтәүне тәэмин итәргә;

каршы як хәрәкәте полосасына чыгып барлыкка килә торган юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү максаты белән, шулай ук юлны чыгу өчен каралмаган урыннарда җәяүлеләрнең машиналар йөри торган өлештән чыгуын чикләү, юл төшү, юл менү участокларында һәм борылышларда транспорт авуын булдырмау өчен барьер тибындагы металл киртәләр һәм җәяүлеләр өчен чикләүләр куюны дәвам иттерергә;

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10сына кадәр Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенә юл-транспорт һәлакәтләре еш була торган урыннарны бетерүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру барышы турында мәгълүматлар кертергә;»;

4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«мәктәп автобусларын «Андроид» операцион системасы базасындагы смартфоннар белән җиһазландыру мөмкинлеген карарга;

2017 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасының муниципаль районнарына һәм шәһәр округларына Татарстан Республикасы территориясендә торак пунктлар яктылыгында, шулай ук республиканың район үзәкләрен тоташтыра торган автомобиль юллары буенда кәрәзле элемтәнең радио капланышы мониторингын тапшырырга;»;

12 нче пунктның унбишенче абзацыннан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10сына кадәр Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенә юл-транспорт һәлакәтләре еш була торган урыннарны бетерүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру барышы турында мәгълүматлар кертергә;»;

12 нче пункта түбәндәге эчтәлекле егерменче – егерме икенче абзацлар өстәргә:

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәге мөмкинлекләрне карарга:

2017 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетын үтәгәндә һәм 2018 елга бюджет формалаштырганда юл-транспорт һәлакәтләре еш була торган урыннарны бетерү буенча чаралар комплексын тормышка ашыруга юнәлдерелгән чараларны финанслау;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчасы исәбеннән юл тамгалары ясау, урам-юл челтәрен карап тоту, юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын кую һәм хезмәт күрсәтү буенча эшләр башкару;

Казан шәһәренең урам-юл челтәрен районнар администрацияләре балансыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты балансына күчерү;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\149.doc